СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**26 февраль 2024 ел** Болгар ш. **№ 37-2**

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 15-2 номерлы Спас муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 15-2 номерлы Спас муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2021 елның 06 декабрендәге 15-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәнең 4 пунктында түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчаны өстәргә:

«5) муниципаль хезмәт Вазыйфаларын алып баручы, өлкән һәм кече төркемгә караган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләгәндә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Спас муниципаль районы Башлыгы,
Советы Рәисе Ф. В. Мөхәмматов